Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# КАРАР

2025 елның 22 ноябре № 5

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 22 ноябрендә уздырылган «Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Кызыл Чапчак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2026 елда 4300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау;
– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
– яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар Җыенының 2024 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карары буенча су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга җыелган 600 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга юнәлдерергә.

«ӘЙЕ» «ЮК».

мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 309 җыенда катнашучы граждан кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан җыенда катнашучы гражданнар саны 160 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучы гражданнар тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 122 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 38 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлеге составына керүче Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар җыенын булган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Түбән Кама муниципаль районының Кызыл Чапчак авыл җирлеге Кызыл Чапчак торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның ире/хатынынннан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүче солдатлардан тыш, 2026 елда 4300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү белән килешәсезме:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр күперләрен һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр җир өсте кичүләрен ремонтлау;
– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
– яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту.

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Кызыл Чапчак авыл җирлегенең Кызыл Чапчак торак пунктында гражданнар Җыенының 2024 елның 15 ноябрендәге 2 номерлы карары буенча су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлауга, төзүгә һәм ремонтлауга җыелган 600 000 сум күләмендәге үзара салым акчаларын торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тотуга юнәлдерергә.

«ӘЙЕ» «ЮК»

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларына һәм Кызыл Чапчак авыл җирлеге сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Кызыл Чапчак авыл җирлеге башлыгы Б.В.Ильдарханов